**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 сентябрендәге 3786 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районында урнашкан җир кишәрлегенә ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 303 кв.м;

- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры - 16:50:100309:9;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;

- билгеләүнең максаты: Казан шәһәре Мәскәү районының Декабристлар, Восстание, Гагарин урамнарында, Ибраһимов проспектында түбән басымлы газ үткәргечләрен күчереп салу (2 нче этап);

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром Трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләүнең нигезләре: гариза бирүченең мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы Федераль законның 3.6 статьясы, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре округының генераль планы, 2022-2028 елларга «Газпром Трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен редукцияләү пунктларын реконструкцияләү программасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, милек

хокукы Совет районының бердәм җитештерү-технология комплексына теркәлгән (2001 елның 10 октябрендәге 16-50.3-23.2001-927.1)

2. Сервитутны башкаруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаган яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 3 ел тәшкил итә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Газпром Трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4 сентябрендәге
3786 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




Масштаб 1:1000
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |

| | |
|---|---|
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдаланунын махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:100309 | кадастр кварталы |
| 16:50:100309:9 | Хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номеры |